| | |
|---|---|
| СОВЕТ МУРАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 01 нче марты Мөрәле авылы № 2

**2017 елның 7 апрелендәге 6 номерлы Татарстан Республикасы Мөрәле авыл җирлеге Советы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы «Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» гы 2017 елның 29 декабрендәге 463-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең аерым закон актлары, "Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы, "Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга карата бердәм таләпләр билгеләү максаты нигезендә, Мөрәле авыл җирлеге Советы **КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. 2017 елның 7 нче апрелендәге 6 нче номерлы "Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче бүлектәге 6 нчы пунктның 4 нче һәм 63 нче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Территорияне төзекләндерү - әлеге кагыйдәләр белән билгеләнгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру эшчәнлеге, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын тәэмин итүгә һәм гражданнарның яшәү шартларын яхшыртуга, торак пунктлар территорияләрен һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны, якын-тирә территорияләрне карап тотуга юнәлтелгән.

Төзекләндерү элементлары – декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җиһазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре һәм шул исәптән биналар, корылмалар фасадлары, кече архитектура формалары капиталь стационар булмаган корылмалар,

мәгълүмат щитлары һәм күрсәткечләр территорияне төзекләндерүнең состав өлешләре буларак кулланыла».

1.2. III нче бүлектәге 27 пунктны түбәндәге эчтәлекле 27.1 пункт асты белән тулыландырырга:

«27.1 Йорт билгеләрендә, тышкы мәгълүмат чараларында мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы закон таләпләрен үтәп урнаштырылырга тиеш. Ике һәм аннан да күбрәк тел куллану очрагында текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча охшаш, дөрес һәм ачык итеп эшләнгән булырга тиеш».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://muralin-kaybici.tatarstan.ru/ һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Мөрәле авыл җирлеге башлыгы** **Р.Р.Зиннатуллин**

Совет Муралинского сельского поселения
Мөрәле авыл җирлеге Советы
ИНН 1621001143